**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР №4**

Иске Каразирек ав. «16» февраль 2026 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советының
2021 елның 25 ноябрендәге 11 санлы карары
белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы “Иске Каразирек авыл җирлеге” муниципаль
берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә
муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

2025 елның 20 мартындагы «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 248-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 294-ФЗ санлы Федераль законы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советы К А Р А Р И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Советының 2021 елның 25 ноябрендәге 11 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында»гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. нигезләмәнең 3.10.5.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10.5.6. Әгәр йөкләмәдә контроль төре һәм (яисә) мәҗбүри профилактик визитлар үткәрелергә тиешле контрольдә тотылучы затлар исемлеге күрсәтелмәгән булса, мондый йөкләмәне үтәүне оештыру максатларында 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 248-ФЗ санлы Федераль законның 52.1 маддәсендәге 7 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары йөкләмәсе кабул ителә.

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгару һәм массакүләм коммуникацияләр чаралары сыйфатында теркәлү турында таныклык (Роскомнадзор) һәм “Рәсми Татарстан” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru/ веб-

адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы И.Р.Гәрәев